**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 24 августы № 21-79

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен түбәндәгеләр өлешендә кабул итү турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу тора.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Яңа Чишмә муниципаль районының вәкаләтле органы белән килешү төзергә;

- 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 елларның планлы чорына җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карары проектын бюджет законнары нигезендә карауга әзерләргә һәм тәкъдим итәргә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру ел саен Яңа Чишмә муниципаль районы җирлеге бюджетыннан Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарныТатарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы В.М. Козлов